ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**26.10.2022** **№ 1032**

**«2023 елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында»**

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 февралендәге 273 номерлы Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2007 елның 11 декабрендәге 448 номерлы «Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елга кушымтада китерелгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карап тотуга норматив чыгымнарны;

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына мәгариф оешмаларын финанслауны мәгариф оешмаларын әлеге карарның 1 нче пунктында расланган норматив чыгымнары нигезендә тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә тарала.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең 2022 елның 26 октябрьдә 1032нче номерлы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карап тотуга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль дислокациясе | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елга сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | авыл җирлеге | 105678 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | авыл җирлеге | 159325 |